ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

ИСКЕ ЙОМРАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ

2026 елның 16 гыйнварындагы 12 номерлы карары

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Иске Йомралы авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2025 елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Иске Йомралы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлегеСоветының 2019 елның 8 ноябрендәге 183 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Иске Йомралы авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.Бюджет акчаларын алучы түбәндәге бюджет вәкаләтләренә ия:

1) РФ Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;

2) бюджет йөкләмәләренең һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләренең җиткерелгән лимитлары чикләрендә бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм (яисә) үти;

3) үзенә каралган бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның нәтиҗәлелеген, максатчан характерын тәэмин итә;

4) бюджет акчаларын тиешле баш бүлүчегә (бүлүчегә) бюджет язмасын үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

5) бюджет исәбен алып бара (бюджет исәбен алып баруны тәэмин итә);

6) бюджет хисабын төзи (бюджет хисабын булдыруны тәэмин итә) һәм бюджет акчаларын алучының бюджет хисабын бюджет акчаларын тиешле баш бүлүчегә (бүлүчегә) тапшыра;

7) РФ Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителгән бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган норматив хокукый актларда (муниципаль хокукый актларда) билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Иске Йомралы авыл җирлеге Башлыгы Р.А.Муратов

СОВЕТ СТАРО-ЮМРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1608000581 ИСКЕ ЙОМРАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ